**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LXIV УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 122**

**Яңа Усы авылы** **«03» февраль 2020 ел**

**Яңа Усы авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 ноябрендәге 89 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Яңа Усы авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 89 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,1 %;»

1. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан җир салымын исәпләүгә бәйле рәвештә хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Яңа Усы авыл җирлеге Башлыгы:** **Г.С.Романова**

районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар закон белән билгеләнгән срокта үз көченә керә.

**Яңа Усы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Г.С.Романова**